ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.12.2022 г. Заинск № 647

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 27 февралендәге 324 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Зәй муниципаль районында мәгариф системасы белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру максатында, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 27 февралендәге 324 номерлы карары (2021 елның 12 ноябрендәге 674 номерлы карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру турында» нигезләмәнең 4.11 пунктында «мәктәпкәчә белем бирүнең тиешле якынча белем бирү программаларын исәпкә алып» сүзләрен «мәктәпкәчә белем бирүнең тиешле

федераль белем бирү программасы» сүзләренә алмаштырырга, түбәндәге эчтәлекле җөмләне өстәргә: «Белем бирү оешмалары тарафыннан эшләнгән белем бирү программаларының эчтәлеге һәм планлаштырылган нәтиҗәләре федераль мәктәпкәчә белем бирү программасының тиешле эчтәлегеннән һәм планлаштырылган нәтиҗәләреннән ким булмаска тиеш.».

2. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э.Р. Сәфәргалиев
3-27-42